Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
К А Р А Р Ы

27 июль 2017 ел №188

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Уставына
үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставының XV бүлеге нигезендә, 2017 елның 27 апрелендәге халык тыңлаулары нәтиҗәләрен исәпкә алып, Әлмәт шәһәре прокурорының 2017 елның 20 февралендәге хатын һәм 2017 елның 26 апрелендәге 430п санлы күрсәтмәсен карап тикшергәннән соң,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләрне кушымта нигезендә кабул итәргә.
2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләрне Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә юлларга.
3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләрне, теркәгәннән соң, «Альметьевский вестник» һәм «Әлмәт таңнары» газеталарында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарга үзгәрешләр 06.10.2003 елгы 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 44 нче маддәсе, 8 нче өлеше нигезендә үз көченә керә.
5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставының 40 нчы маддәсе, 2, 3 нче өлешләрендәге, 73 нче маддәсе, 3 нче өлешендәге, 92 нче маддәсе, 3 нче өлеше, беренче абзацындагы, 4, 5 нче өлешләрендәге үзгәрешләр 2017 елның 18 июлендәге 171-ФЗ санлы «РФдә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү

турында»гы Федераль закон үз көченә керүне исәпкә алып, 2017 елның 30 июленнән соң барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

6. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башлыгы урынбасары А.А. Зиминга йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2017 елның 27 июлендәге 188 санлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр

1) 6 нчы маддәнең 1 нче өлеше 10 нчы пунктында «каникул вакытында балаларның ялын оештыру» дигән сүзләрне «каникул вакытында балаларның ялын оештыру буенча чараларны, аларның тормышы һәм сәламәтлеге куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чараларны да кертеп, үз вәкаләтләре чикләрендә тормышка ашыру» дигән сүзләр белән алыштырырга;

2) 16 нчы маддәнең 3 нче өлеше 1 нче пунктын түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«1) район Уставы проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты, район Уставына үзгәрешләр Уставны әлеге норматив хокукый актлар белән туры китерү максатларында Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яки законнары положениеләрен төгәл кабатлау рәвешендә кертелә торган очраклардан кала;»;

3) 26 нчы маддәнең исемен түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«26 нчы маддә. Район Советы депутаты, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарә сайланулы вазифаи заты статусы.»;

4) 26 нчы маддәдә:

а) 2 нче өлешнең 2 нче пунктын түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«2) шәхсән яки ышанычлы затлар аркылы эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерциячел оешма белән идарә итүдә яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләре, сәяси партия белән идарә итүдән, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары, күчемсез милек милекчеләре ширкәте гомуми җыелышында катнашудан башка), федераль законнарда күздә тотылган очраклардан һәм оешма белән идарә итүдә катнашу җирле үзидарә органы исеменнән Россия Федерациясе законнары нигезендә тормышка ашырылган очраклардан кала;»;

б) түбәндәге эчтәлектәге 8, 9, 10 нчы өлешләр белән тулыландырырга:

«8. Депутат, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарә сайланулы вазифаи заты тарафыннан коррупциягә каршы тору турындагы

Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган аларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм милек характерындагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы дәүләт власте югары башкарма органы җитәкчесе) карары буенча Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

9. Әлеге маддәнең 7 нче өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы «Коррупциягә каршы тору турында»гы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ санлы «Дәүләт вазифаларын биләүче һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүгә контроль турында»гы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ санлы «Кайбер категория кешеләргә счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, кулдагы акча средстволарын һәм кыйммәтләрне Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында»гы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләр, тыюларны сакламау, вазифаларны үтәмәү фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы дәүләт власте югары башкарма органы җитәкчесе) депутатның, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасының, җирле үзидарә сайланулы вазифаи затының вәкаләтләрен срогыннан алда туктату турында гариза белән тиешле карар кабул итәргә вәкаләте булган җирле үзидарә органына яки судка мөрәҗәгать итә.

10. Муниципаль вазифаларны биләүче затлар тарафыннан бирелгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм милек характерындагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр җирле үзидарә органының интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла һәм (яки) бастырып чыгару өчен, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә, массакүләм мәгълүмат чараларына бирелә.»;

5) 29 нчы маддәнең 1 нче өлешендә 20, 23 нче пунктларны алып ташларга;

6) 35 нче маддәнең 2 нче өлешен түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы дәүләт власте югары башкарма органы җитәкчесе) район Советы депутатының вәкаләтләрен срогыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта вәкаләтләрне срогыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көн итеп әлеге гариза район Советына кергән көн санала.»;

7) 36 нчы маддәнең 2 нче өлешендә «хәлиткеч тавыш хокукы белән» дигән сүзләрне алып ташларга;

8) 38 нче маддәдә:
а) 2 нче өлешнең 2 нче пунктын түбәндәге укылышта бәян итәргә:
«2) шәхсән яки ышанычлы затлар аркылы эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерциячел оешма белән идарә итүдә яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләре, сәяси партия белән идарә итүдән, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача куллануычылар кооперативлары, күчемсез милек милекчеләре ширкәте гомуми җыелышында катнашудан башка), федераль законнарда күздә тотылган очраклардан һәм оешма белән идарә итүдә катнашу җирле үзидарә органы исеменнән Россия Федерациясе законнары нигезендә тормышка ашырылган очраклардан кала;»;

б) 5 нче өлештә «һәм башка федераль законнар белән» дигән сүзләрне алып ташларга;

9) 40 нчы маддәнең 2, 3 нче өлешләрен түбәндәге укылышта бәян итәргә:
«2. Район башлыгының вәкаләтләре срогыннан алда туктатылган очракта район Советы тарафыннан үз составыннан сайлана торган район башлыгын сайлау вәкаләтләр туктатылган көннән алып алты айдан да соңга калмыйча башкарыла.
3. Район Советы вәкаләтләренең срогы чыгуга алты айдан ким вакыт калган булса, район Советы составыннан район башлыгын сайлау яңа сайланган район Советының беренче утырышында башкарыла.»;

10) 41 нче маддәнең 3 нче өлешен түбәндәге укылышта бәян итәргә:
«3. Район башлыгы урынбасары район Советы Регламенты белән билгеләнгән вазифаларның бүленеше нигезендә эшли, район башлыгының күрсәтмәләрен үти, ә ул вакытлыча булмаган (авырып китү сәбәпле яки чираттагы ял белән бәйле рәвештә), аның үз вазифаларын үтәү мөмкинлеге булмаган, вәкаләтләре срогыннан алда туктатылган, суд карары белән аңа карата сак астына алу яки вазифасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылган очракта район башлыгы вазифаларын башкара.»;

11) 44 нче маддәдә:
а) 5 нче пунктның 7 нче абзацын түбәндәге укылышта бәян итәргә:
«- энергияне янга калдыру һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру өлкәсендә муниципаль программаларны раслый һәм тормышка ашыра, бүлмәләре район чикләрендәге муниципаль торак фондын тәшкил итүче күпфатирлы йортларда энергетик тикшерүләр үткәрүне оештыра, энергияне янга калдыру турындагы һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру турындагы законнарда күздә тотылган башка чараларны оештыра һәм үткәрә;»;

б) 1 нче өлешнең 7 нче пункты 4 нче абзацында «каникул вакытында балаларның ялын оештыру» дигән сүзләрне «каникул вакытында балаларның ялын оештыру буенча чараларны, аларның тормышы һәм сәламәтлеге куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чараларны да кертеп, үз вәкаләтләре чикләрендә тормышка ашыра» дигән сүзләр белән алыштырырга;

в) 8 нче пунктны түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«8) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау, законлылыкны тәэмин итү, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә:

- инвалидлар иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук инвалидларның гомумроссия иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан булдырылган оешмаларга 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында»гы Федераль закон нигезендә булышлык күрсәтә;
- район территориясендә дәүләт власте һәм җирле үзидарә органнары законнары, актларының үтәлешен, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклауны тәэмин итә;
- дәүләт власте органнары һәм дәүләт вазифаи затларының, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмаларның җирле үзидарә хокукларын бозучы актларын билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән судта яки арбитраж судында карауга шикаять бирә;
- федераль закон нигезендә муниципаль милиция тарафыннан җәмәгать тәртибен саклауны оештыруны тәэмин итә;
- район чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтүдә һәм нәтиҗәләрен бетерүдә катнаша;
- территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы, район халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча чараларны оештыра һәм тормышка ашыруны тәэмин итә; гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бетерү өчен җирле финанс һәм матди ресурслар резервларын булдыруны тәэмин итә;
- үз вәкаләтләре чикләрендә һәм билгеләнгән тәртиптә гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы яки гадәттән тыш хәл килеп чыгу турында халыкка үзвакытында хәбәр итүне һәм кешеләрне хәбәрдар итүне тәэмин итә;
- су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү, тормышларын һәм сәламәтлекләрен саклау буенча чараларны тормышка ашыруны тәэмин итә;
- опека һәм попечительлекне тормышка ашыра;
- муниципаль сайлауларны, җирле референдумны, район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне әзерләү һәм үткәрүнең оештыру һәм матди-техник тәэмин ителешен тормышка ашыра;
- Россия Федерациясенең су турындагы законнары белән билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесе вәкаләтләрен тормышка ашыра, гомуми файдаланудагы су объектларын шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен билгели;

- муниципаль район территориясендә терроризм һәм экстремизмны кисәтүдә, шулай ук терроризм һәм экстремизм чагылышларын минимальләштерүдә һәм (яки) нәтиҗәләрен бетерүдә катнаша;

- терроризмны кисәтү, шулай ук аның чагылышын минимальләштерү һәм (яки) нәтиҗәләрен бетерү өлкәсендә муниципаль программаларны эшли һәм тормышка ашыра;

- муниципаль берәмлекләрдә, шул исәптән мәгълүмати материаллар, басма продукция тарату, аңлату эшләре алып бару һәм башка төрле чаралар юлы белән, терроризмның асылын һәм иҗтимагый куркынычын аңлату, шулай ук гражданнарда терроризм идеологиясенә тискәре караш формалаштыру буенча мәгълүмати-пропагандистлык чаралары оештыра һәм үткәрә;

- терроризмны кисәтү, шулай ук аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яки) нәтиҗәләрен бетерү буенча башкарма власть федераль органнары һәм (яки) Татарстан Республикасы башкарма власть органнары тарафыннан оештырыла торган чараларда катнаша;

- муниципаль милектә яки җирле үзидарә органнары карамагында булган объектларның терроризмга каршы сакланышына карата таләпләрнең үтәлешен тәэмин итә;

- терроризмны кисәтүдә, шулай ук аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яки) нәтиҗәләрен бетерүдә катнашу мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы башкарма власть органнарына юллый;

- терроризмны кисәтүдә, шулай ук аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яки) нәтиҗәләрен бетерүдә катнашу буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча башка вәкаләтләрне тормышка ашыра;

- район чикләрендә коррупциягә каршы тору буенча чараларны тормышка ашыра;

- муниципаль район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телен һәм мәдәниятен саклап калу һәм үстерүгә, милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) низагларны кисәтүгә юнәлдерелгән чараларны эшли һәм тормышка ашыра;

- район территориясендәге муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләрнең мобилизацион хәзерлеге буенча чараларны оештыра һәм тормышка ашыра;

- «Россия Федерациясендә хокук бозуларны кисәтү системасы нигезләре турында»гы Федераль законда күздә тотылган хокук бозуларны кисәтү өлкәсендә чараларны тормышка ашыра;»;

г) 2 нче өлешнең 2 нче пунктын түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«2) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау, законлылыкны тәэмин итү, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә:

- авыл җирлекләре чикләрендә терроризм һәм экстремизмны кисәтүдә, шулай ук терроризм һәм экстремизм чагылышларын минимальләштерүдә һәм (яки) нәтиҗәләрен бетерүдә катнаша;

- терроризмны кисәтү, шулай ук аның чагылышын минимальләштерү һәм (яки) нәтиҗәләрен бетерү өлкәсендә муниципаль программаларны эшли һәм тормышка ашыра;

- муниципаль берәмлекләрдә, шул исәптән мәгълүмати материаллар, басма продукция тарату, аңлату эшләре алып бару һәм башка төрле чаралар юлы белән, терроризмның асылын һәм иҗтимагый куркынычын аңлату, шулай ук гражданнарда терроризм идеологиясенә тискәре караш формалаштыру буенча мәгълүмати-пропагандистлык чаралары оештыра һәм үткәрә;

- терроризмны кисәтү, шулай ук аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яки) нәтиҗәләрен бетерү буенча башкарма власть федераль органнары һәм (яки) Татарстан Республикасы башкарма власть органнары тарафыннан оештырыла торган чараларда катнаша;

- муниципаль милектә яки җирле үзидарә органнары карамагында булган объектларның терроризмга каршы сакланышына карата таләпләрнең үтәлешен тәэмин итә;

- терроризмны кисәтүдә, шулай ук аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яки) нәтиҗәләрен бетерүдә катнашу мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы башкарма власть органнарына юллый;

- терроризмны кисәтүдә, шулай ук аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яки) нәтиҗәләрен бетерүдә катнашу буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча башка вәкаләтләрне тормышка ашыра;

- авыл җирлекләре чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтүдә һәм нәтиҗәләрен бетерүдә катнаша;

- авыл җирлекләре милкендә булган мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) сакланышын, файдаланылуын һәм популярлаштыруны, авыл җирлекләре территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) сакланышын тормышка ашыра;

- территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы, авыл җирлекләре халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча чараларны оештыра һәм тормышка ашыруны тәэмин итә; гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бетерү өчен җирле финанс һәм матди ресурслар резервларын булдыруны тәэмин итә;

- авыл җирлекләре территориясендә авария-коткару службаларын һәм (яки) авария-коткару берләшмәләрен булдыра, аларны тотуны һәм эшчәнлеген оештыруны тәэмин итә;

- су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү, тормышларын һәм сәламәтлекләрен саклау буенча чараларны тормышка ашыруны тәэмин итә;

- Россия Федерациясенең су турындагы законнары белән билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесе вәкаләтләрен тормышка ашыра, алардан файдалануны чикләү турында халыкка хәбәр итә;»;

12) 45нче маддәдә:

а) 5 нче өлешен «яки вәкаләтләрне срогыннан алда туктату» дигән сүзләрдән соң «яки суд карары буенча аңа карата сак астына алу яки вазифасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары куллану» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

б) 6 нчы өлешен түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«6. Район башкарма комитеты җитәкчесе 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы «Коррупциягә каршы тору турында»гы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ санлы «Дәүләт вазифаларын биләүче һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүгә контроль турында»гы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ санлы «Кайбер категория кешеләргә счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, кулдагы акча средстволарын һәм кыйммәтләрне Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында»гы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны сакларга, вазифаларны үтәргә тиеш;

13) 49 нчы маддәне түбәндәге эчтәлектәге 3 нче өлеш белән тулыландырырга:

«3. Район башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт коррупциягә каршы тору турындагы РФ законнары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм милек характерындагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы «Коррупциягә каршы тору турында»гы ФЗ, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ санлы «Дәүләт вазифаларын биләүче һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүгә контроль турында»гы ФЗ, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ санлы «Кайбер категория кешеләргә счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, кулдагы акча средстволарын һәм кыйммәтләрне РФ территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында»гы ФЗ белән билгеләнгән чикләүләр, тыюларны сакламау, вазифаларны үтәмәү белән бәйле рәвештә, ТР Президентының (ТР дәүләт власте югары башкарма органы җитәкчесенең) гаризасы нигезендә суд тәртибендә өзелергә мөмкин»;

14) 65.1 маддәсенең 2 нче өлеше 4 нче пунктын түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«4) 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы «Коррупциягә каршы тору турында»гы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ санлы «Дәүләт вазифаларын биләүче һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүгә контроль турында»гы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ санлы «Кайбер категория кешеләргә счетлар (кертемнәр) ачуны һәм

булдыруны, кулдагы акча средстволарын һәм кыйммәтләрне Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында»гы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләр, тыюларны сакламау, вазифаларны үтәмәү»;

15) 73 нче маддәнең 3 нче өлешен түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«3. Кешенең һәм гражданинның хокукларына, ирегенә һәм бурычларына кагыла торган, муниципаль берәмлек гамәлгә куйган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр аларны рәсми бастырып чыгарганнан (халыкка җиткәргәннән) соң үз көченә керә.»;

16) 90 нчы маддәдә:

а) 3 нче өлешнең икенче җөмләсен түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«Район Уставына үзгәрешләр Уставны әлеге норматив хокукый актлар белән туры китерү максатларында РФ Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яки законнары положениеләрен төгәл кабатлау формасында кертелгән очракта район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук гражданнарның аны тикшерүдә катнашуы тәртибен рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.»;

б) түбәндәге эчтәлектәге 5 нче өлеш белән тулыландырырга:

«5. Район Уставын федераль закон, Татарстан Республикасы Законы белән туры китерү әлеге закон чыгару актлары белән билгеләнгән срокта башкарыла. Әгәр федераль закон, Татарстан Республикасы законы белән әлеге срок билгеләнмәгән булса, район Уставын федераль закон, Татарстан Республикасы Законы белән туры китерү срогы тиешле федераль закон, Татарстан Республикасы законы үз көченә кергән датаны, район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм халык тыңлауларында тикшерү, гражданнарның анын буенча тәкъдимнәрен, район Советы утырышларының эзлеклелеген, андый карарны дәүләт теркәве һәм рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) срокларын исәпкә алып билгеләнә һәм, кагыйдә буларак, алты айдан артык булырга тиеш түгел.»;

17) 92 нче маддәдә:

а) 1 нче өлештә «башкарма власть өлкәсендә» дигән сүзләрне алып ташларга;

б) 3 нче өлешнең беренче абзацын түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«3. Район Уставына кертелгән һәм җирле үзидарә органнарының төзелешен, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүленешен үзгәртүче (район Уставын федераль законнарга туры китерү,шулай ук җирле үзидарә сайланулы вазифаи затлары вәкаләтләрен,вәкаләтләр срогын, аларны сайлау тәртибен үзгәртү очракларыннан кала) үзгәрешләр һәм өстәмәләр район Уставына әлеге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертү турында муниципаль

хокукый актны кабул иткән район Советының вәкаләтләре срогы чыкканнан соң үз көченә керә.»;

в) түбәндәге эчтәлектәге 4, 5 нче өлешләр белән тулыландырырга:

«4. Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр түбәндәгеләр тарафыннан теркәлә ала торган муниципаль хокукый акт белән кертелә:

1) район Советы рәисе вәкаләтләрен башкаручы район башлыгы үзе кул куйган район Советы карары белән;

2) район Советы тарафыннан кабул ителгән һәм район башлыгы кул куйган аерым норматив хокукый акт белән. Бу очракта әлеге хокукый актта аны кабул итү турындагы район Советы карарының реквизитлары куела. Андый район Советы карарына муниципаль берәмлек уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләрнең үз көченә керүе турында күчмә положениеләр һәм (яки) нормалар кертү рөхсәт ителми.

5. Район Уставын район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт белән яңа укылышта бәян итү рөхсәт ителми. Бу очракта районның яңа Уставы кабул ителә, ә элек гамәлдә булган район Уставы һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актлар районның яңа Уставы үз көченә кергән көннән көчен югалткан дип таныла.».

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин